# ХЫЯЛ

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ**
**“ЧАЛМАНАРАТ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”НЕҢ**
**АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ**


## 4 нче ноябрь – Халыклар бердәмлеге көне




**4 нче ноябрь** – Халыклар бердәмлеге көне. Аның тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Ул тынычлык, иминлек, бәйсезлек өчен бердәмлек символын чагылдыра.

Дәүләт күләмендәге бу бәйрәм 1612 нче елгы тарихи вакыйгаларга барып тоташа. Халыкара бердәмлек көне буларак, 2005 нче елдан билгеләп үтелә.

Безнең ата-бабаларыбыз – төрле милләт, дин һәм төрле катлам вәкилләре, бер булып, уртак Ватаныбызны чит илбасарлардан азат иткән. Төрле милләт кешеләренең берләшүе, Ватанны яратуы илебезгә тарих сынауларын җиңеп чыгарга ярдәм иткән.

Уртак көч булып туплансак, авыр чакта бер-беребезгә ярдәм кулы сузсак, җәмгыятебездәге вакыйгаларга битарафлык күрсәтмәсәк, төрле дин һәм милләт халкына, аларның гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карасак, без – көчле халык.

Иң мөһиме – кыйблабыз ачык, туры булсын. Аңлашып яшәсәк кенә, тормышыбыз рухи һәм икътисади яктан алга китәр.

## 6 нчы ноябрь – ТР Конституциясе көне





**6 нчы ноябрь** – ТР Төп Законын кабул итү көне.

Төп Законыбыз 7 кисәк, 4 бүлек, 126 маддәдән тора.

1992 нче елның 6 нчы ноябрендә ТР ның Югары Совет тарафыннан кабул ителә...

Конституция, ТРның күпмилләтле халкы һәм татар халкы ихтыярын чагылдырып,

- кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең өстенлеген гамәлгә ашыра,
- халыкларның гомумтаныл-ган үзбилгеләнү хокукына, аларның тигез хокуклылыгы, ихтыяр белдерүнең ирекле леге һәм бәйсезлеге принципларына нигезләнә,
- тарихи, милли һәм рухи традицияләрнең, мәдәниятләр-нең, телләрнең сакланып калуына һәм үсешенә, гражданнар татулыгын һәм милләтара килешүне тәэмин итүгә ярдәм итә,
- демократиянең ныгуына, ТРның социаль-икътисадый үсешенә, РФ халыкларының федерализм принципларында тарихи барлыкка килгән бердәмлеген саклап калуга шартлар булдыра.




# Әниләр көне

Мәктәп күләмендә “Әниләр бәйрәме” уздырылды. Кичә укучыларның концерт номерлары һәм уеннар белән үрелеп барды. Барлык әниләрне бәйрәм белән котлыйбыз!

Д.Акбулатова

- Анаң өчен уч төбендә тәбә куырсаң да, бурычыңны кайтара алмассың.

-Әнкәм йорты алтын бишек.

- Үз анасын зурлаган, кеше анасын хурламас.



- Атаңны башыңда тот, Анаңны учыңда тот!

- Ана — шәфкать диңгезе.

- Ана яхшылыгын авырсаң белерсең.

## Минем әнием

Әнием - дөньяда иң назлы, иң сөйкемле, мәрхәмәтле әниләрнең берсе. Ул бар җиһанны яктырта. Назлы карашы белән күңелемне җылыта. Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә.

**А.Манихова**

05.png

## Әнием генә белә

Ул шатлыгымны да, уйларымны да белә. Аның ягымлы тавышы да миңа шатлык кына китерә. Йомшак куллары белән башымнан сыйпаса да, миңа бик рәхәт була.

**С. Шакиров**

06.png

## Әниемне яратам

Әнием мине яхшылык белән начарлыкны аерырга өйрәтә. Аның кочагына сыенып, сөю назында коенам.

Кайтуымны көтеп тора ул.

**Д.Акбулатова.**

01.png

## Кадерлем минем

Әнием, зур рәхмәт сиңа. Киңәшләреңсабырлыгың белән үрнәк булып, бер дә авырмыйча, безнең өчен гел сөенеп яшә. Без сине бик яратабыз. Әниләр бәйрәме белән сине!

**И.Локманов**

02.png

## Әниемнең назы

Әнием мин сине бик яратам. Ягымлы карашың, тәмле ашларың, авырганда яныбыздан китмәвеңне онытмабыз, йөзеңә кызыллык китермәбез.

**З.Гәрәев**

03.png

## Кояшым минем

Әниләрне ярату гына аз, аларның кадерен белергә кирәк. Кичен назлап йоклатучы, иртән “кызым” дип сөеп уятучы җылы кояшым ул - әнием.

**А.Хәбирова**

04.png



4 нче класс укучысы Энҗе Инзир кызы Вәлиева, әниләр көненә багышлап, район күләмендә уздырылган “Тормышның бөтен төсләре сиңа” дигән балалар иҗаты конкурсының “Панно” номинациясендә – I; “Барысы да аның турында” дигән темага сочинение язуда III урын алды.

Зарипов Раил



3 нче класс укучысы Нәфкәт Шамил улы Булатов, әниләр көненә багышлап, район күләмендә уздырылган “Барысы да аның турында” дигән темага сочинение язуда II урын алды.

Гәрәев Зөлфәт.

## ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

### Ничә алма?



*Ике алмагач үсеп утыра. Берсендә сары алмалар, икенчесендә кызыл... грушалар. Юк, шаяртабыз, алмалар, билгеле. Балалар барлык җимешләрне җыеп алганнар. Һәр 4 сары алмага 5 кызыл туры килгән. 16шар сары һәм кызыл алманы ашагач, һәр 2 сары җимешкә 3 зәңгәр туры килә. Барысы ничә алма?*






**Кыш**

Менә кыш килеп җитте,
Урам карга төренде.
Тышта бер бала уйный
Кар бабай ясап туймый.
Аннан эшләп бетергәч,
Күз алмый карап тора.
Аннан балалар килгәч,
Кар бабайга соклана.

**Яз.**

Менә яз килеп җитте,
Карлар да эреп бетте.
Балаларның таулары
Су белән агып китте.
Балалар куаналар,
Хәзер җәй килеп җитә.
Җылы җәй көне шулай
Күңелле була бик тә.

**Манихова Адилә**
**6 нчы класс**



**Китап - белем чишмәсе**

Китап - белем чишмәсе,
Чишмәсе татлы аның.
Татып карасаң әгәр
Яратырсың китапны.
Бөтен гомереӊ буена.

**Әхмәтхуҗин Камил.**
**5 нче класс**

**Кешенең дусты – китап**

Кешенең дусты – китап,
Төшермә син аңа тап.
Ямансулап утырганда,
Ал да укы син китап.

**Хәбирова Айзилә**
**5 нче класс**



**Җәй.**

Менә җәй килеп җитте,
Барлык җиргә ямь керде.
Балалар су керәләр,
Чумалар, сикерәләр.
Шундый рәхәт җылы су,
Чөнки җәй шундый кызу.
Күктә болыт зәңгәрсу,
Урамда уйный Алсу.

**Көз.**

Агач яфрак коя,
Җил исә, яңгыр ява.
Менә шулай көз көне
Һава үзгәреп тора.
Агачта яфрак калмаган,
Җил аны алып киткән.
Яңгыр ява, кояш чыга,
Чөнки көз килеп җиткән.

**Манихова Адилә**
**6 нчы класс**



# Файдалы киңәшләр



Алма, груша, хөрмә, кавын, чия, кара җиләк, кыяр, чөгендер баш миен яхшы эшләтә, хәтерне яхшырта һәм склероздан саклый.

*Кара җиләк, япон айвасы күзләргә файдалы.*

Кыяр чәчне үстерә.

*Кыяр, шалкан тешләрне ныгыта.*

Йөзем, грейпфрут, каен җиләге организмны ныгыта.

*Карбыз организмнан агулы матдәләрне чыгарырга булыша.*

«Хыял» Чалманарат төп гомуми белем бирү укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы
Шеф-мөхәррир: Диана Акбулатова Җаваплы сәркатип: Миләүшә Фазлыева Фотохәбәрче: Сәйдәш Шакиров
Безнең адрес: 423752, Чалманарат авылы, Мәктәп ур., 7 нче йорт. E-mail: Schal.Akt@edu.tatar.ru, chalm.akt@yandex.ru
Тираж: 15 данә Кул куелды: 08.00; 30.11.2017
Мәктәп компьютерында басылды. Бәясе ирекле. Мәкаләдәге фикерләр өчен мөхәррият җавап тотмый.